| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.10.2023** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3136** |
|---|---|---|

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 ноябрендәге 3140 номерлы карары белән расланган, 2023 елга 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәре баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясындагы 3[2] пунктының дүртенче абзацы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 ноябрендәге 3140 номерлы карары белән расланган «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында»(2022 елның 27 декабрендәге 3553 номерлы, 2023 елның 16 гыйнварындагы 30 номерлы, 2023 елның 01 февралендәге 167 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына төп администраторлары исемлегенә( (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «805 | 2 02 27576 05 0000 150 | Авыл территорияләрен комплекслы үстерүне тәэмин итү кысаларында дәүләт (муниципаль) милке объектларына капитал салуларны финанслашуга муниципаль районнар бюджетларына субсидияләр |
| 805 | 2 02 45179 05 0000 150 | Гомуми белем бирү оешмаларында балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү һәм тәрбияләү буенча директорларның киңәшчеләре эшчәнлеген тәэмин итү чараларын үткәрүгә муниципаль районнар бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2023 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин